# “Тел сагында ир егетләр”

11 нче март көнне МБОУ "187 нче күп профильле лицей"да шәһәр күләмендә оештырылыла торган " Тел сагында ир- егетләр" конкурсы булып узды. Әлеге бәйге бишенче ел рәттән бара. Быелгы бәйгене Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышладылар. Бу бәйгене бик яратып кабул иттеләр, шуңа күрә укытучылар бик теләп катнашалар. Сәхнәдә 4 районнан берәр команда катнашты. Конкурсның шарты һәр командада бары ир-егетләр генә булырга тиеш, татар телендә камил аралаша торган педагоглар булырга тиеш. Безнең район данын яклап чыгучы ир-егетләр командасы 171 нче мәктәп укытучылары булды. Алар чынлап торып үзләренең хезмәтләренең осталыгын исбатлап, профессионал артист кебек, югары дәрәҗәдә чыгыш ясадылар. Барлык бирелгән биремнәрне дөрес үтәп, югары баллар яуладылар. 171 нче мәктәп ир-егетләре Гран- при исеменә лаек булды. “Тел сагында ир егетләр” шәһәр конкурсының Юбилей чыгарылышы безнең лицей залында узуы белән горурланабыз. Безнең укытучыларыбыз да үзләренә зур тәҗрибә алдылар.






Тел сагында –
ир-егетләр